**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Экологический кодекс Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
14 июля 2022 года

**Статья 1**

Внести в Экологический кодекс Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 1; 2010, № 5 (I часть); 2011, № 6 (I часть), № 10 (I часть); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 40 (часть I), № 44 (часть I); 2017, № 27 (часть I); 2018, № 54 (часть I); 2019, № 2 (часть I), № 19 (часть I); 2020, № 4 (часть I), № 37 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I); 2021, № 20 (часть I), № 57 (часть I), № 93 (часть I); 2022, № 34 (часть I) следующие изменения:

1) в части 1 статьи 8:
а) абзац двенадцатый изложить в следующей редакции:
«предъявление исков о возмещении вреда, причиненного окружающей среде вследствие нарушений обязательных требований;»;
б) дополнить новым абзацем тридцать девятым следующего содержания:
«утверждение по согласованию с уполномоченным Правительством Российской Федерации федеральным органом исполнительной власти плана мероприятий Республики Татарстан по выявлению и оценке объектов накопленного вреда окружающей среде, и (или) организации работ по ликвидации накопленного вреда окружающей среде, и (или) осуществлению иных мероприятий по предотвращению и (или) снижению негативного воздействия хозяйственной и иной деятельности на окружающую среду, сохранению и восстановлению природной среды, рациональному использованию и воспроизводству природных ресурсов, обеспечению экологической безопасности;»;
в) абзац тридцать девятый считать абзацем сороковым;

2) в статье 46:
а) в пункте 2 части 1 слова «и ее компонентам» исключить;

б) в части 2 слова «и ее компонентам» исключить;

3) часть 2 статьи 91 изложить в следующей редакции:

«2. При использовании водных объектов физические лица, юридические лица обязаны осуществлять мероприятия по изучению, использованию, охране водных объектов, находящихся в государственной или муниципальной собственности, а также по предотвращению негативного воздействия вод и ликвидации его последствий (далее – водохозяйственные мероприятия) в соответствии с федеральным законодательством.»;

4) в пункте 1 части 13 статьи 98 слова «регулирования плодородия почв» заменить словами «повышения почвенного плодородия»;

5) в статье 100:

а) часть $1^1$ изложить в следующей редакции:

«$1^1$. В целях предотвращения негативного воздействия вод на определенные территории и объекты и ликвидации его последствий осуществляются предусмотренные статьей $67^1$ Водного кодекса Российской Федерации мероприятия по предотвращению негативного воздействия вод и ликвидации его последствий.»;

б) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. Указанные в части $1^1$ настоящей статьи мероприятия осуществляются в рамках водохозяйственных мероприятий, предусмотренных статьей $7^1$ Водного кодекса Российской Федерации.».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением положений, для которых настоящей статьей установлены иные сроки вступления их в силу.

2. Абзацы первый, четвертый – шестой пункта 1 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 сентября 2022 года.

3. Абзацы второй и третий пункта 1 и пункт 2 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 сентября 2023 года.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
25 июля 2022 года
№ 44-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 14 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 1 өлешендә:

а) уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны каплау турында дәгъвалар бирү;»;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа утыз тугызынчы абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы белән килештереп, әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм бәяләү, һәм (яисә) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерү эшләрен оештыру, һәм (яисә) хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмый калуның һәм (яисә) киметүнең, табигый мохитне саклауның һәм торгызуның, табигать ресурсларыннан рациональ файдалануның һәм аларны торгызуның, экологик иминлек тәэмин итүнең башка чараларын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасының чаралар планын раслау;»;

в) утыз тугызынчы абзацны кырыгынчы абзац дип санарга;

2) 46 статьяда:

а) 1 өлешнең 2 пунктында «һәм аның компонентларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «һәм аның компонентларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 91 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Су объектларыннан файдаланганда, физик затлар, юридик затлар дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге су объектларын өйрәнү, алардан файдалану, аларны саклау, шулай ук суларның тискәре йогынтысын булдырмый калу һәм аннан килгән зыяннарны бетерү гамәлләрен (алга таба – суга кагылышлы хуҗалык гамәлләре) федераль законнар нигезендә башкарырга тиеш.»;

4) 98 статьяның 13 өлешендәге 1 пунктында «туфракның уңдырышлылыгын көйләү» сүзләрен «туфрак уңдырышлылыгын арттыру» сүзләренә алмаштырырга;

5) 100 статьяда:

а) $1^1$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$1^1$. Суларның аерым территорияләргә һәм объектларга тискәре йогынтысын булдырмый калу һәм аннан килгән зыяннарны бетерү максатларында суларның тискәре йогынтысын булдырмый калу һәм аннан килгән зыяннарны бетерү буенча Россия Федерациясе Су кодексының $67^1$ статьясында каралган чаралар гамәлгә ашырыла.» ;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге статьяның $1^1$ өлешендә күрсәтелгән чаралар Россия Федерациясе Су кодексының $7^1$ статьясында каралган суга кагылышлы хуҗалык гамәлләре кысаларында гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының беренче, дүртенче – алтынчы абзацлары 2022 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының икенче һәм өченче абзацлары һәм 2 пункты 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 25 июль
№ 44-ТРЗ